**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4115**
**09.06.2025**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган күпфатирлы йортларга янәшә территорияләр чикләрен билгеләү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләти җайга салу турында һәм алкогольле продукция куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Алкогольле продукцияне ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшә территорияләрнең чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы карары, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сату вакытын, шартларын һәм урыннарын өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актлары үз көчен югалтуны тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Законы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшә территорияләр чикләрен билгеләү буенча махсус комиссиянең 2025 елның 28 февралендәге утырышы беркетмәсе нигезендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган күпфатирлы йортларга янәшә территорияләр чикләрен билгеләү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен исәпкә алып,

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә, килүчеләргә хезмәт күрсәтү буенча сезонлы зал (зона) мәйданын исәпкә алмыйча, килүчеләргә хезмәт күрсәтү буенча 100 квадрат метрдан кимрәк залы булган җәмәгать туклануы объектларында җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә, алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган күпфатирлы йортларга янәшә территорияләр чикләрен күпфатирлы йортлар биналарыннан 20 метр ераклыкта билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ераклык, ясалма һәм табигый киртәләрне исәпкә алмыйча, күпфатирлы йорт бинасының (стенасының) иң якын ноктасыннан туры сызык буенча җәмәгать туклануы объектына килүчеләр өчен керү урынына кадәр радиус буенча билгеләнә дип билгеләргә.

Туры сызык буенча үлчәүне үткәрү мөмкин булмаган очракта, ераклыкны үлчәү Татарстан Республикасы гавами кадастр картасының «линейка» инструменты ярдәмендә башкарыла.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов